КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1140

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшчәнлеге өлкәсендә идарә итү буенча, Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару буенча, махсус сакланыла торган

табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча, үсемлекләр дөньясыннан файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу буенча, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендәге товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча максатларның һәм бурычларның өстенлеген тәэмин итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы, шулай ук Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген (Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрендәге хайваннар дөньясы объектларыннан һәм аларның яшәү тирәлегеннән тыш) саклау, торгызу һәм файдалану өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), Татарстан Республикасы территориясендә (федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләреннән тыш) федераль дәүләт аучылык контроле (күзәтчелеге), эчке су объектларында су биологик ресурсларын саклау буенча вәкаләтләрен үтәүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора.»;

2.1 пунктның өченче абзацында «контрольдә тотуны һәм күзәтчелек итүне» сүзләрен «дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотуны» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

җиденче абзацта тиешле килештәге «күзәтчелеге» сүзен «контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга, «төбәк әһәмиятендәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә тапшырылган вәкаләтләр чикләрендә федераль дәүләт аучылык контроле (күзәтчелеге) (федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләреннән тыш) (01.06.18).»;

4.1 пунктта:

4.1.1 пунктчада:

«күзәтчелеге» сүзен «контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

«саклау» сүзләреннән соң «, торгызу» сүзләрен өстәргә;

4.1.4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.4. Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, файдалану һәм торгызу өлкәсендә контрольдә тоту һәм күзәтчелек итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнары белән килештереп, Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясыннан файдалануга чикләүләр (аучылыкка һәм балыкчылыкка чикләүләрдән, федераль әһәмияттәге аеруча сакланыла торган табигать территорияләрендә, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда башка җирләрдә хайваннар дөньясыннан файдалануга чикләүләрдән тыш) билгеләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертү;»;

4.1.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.6. Татарстан Республикасы чикләрендә хайваннар дөньясы объектларының дәүләт мониторингын һәм дәүләт кадастрын (федераль әһәмияттәге аеруча сакланыла

торган табигать территорияләрендәге, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда башка җирләрдәге хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) һәм Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларының дәүләт кадастрын алып бару;»;

4.1.14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.14. Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары проектларын законнар белән билгеләнгән тәртиптә үз вәкаләтләре чикләрендә эшләү һәм кертү, шулай ук билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә норматив хокукый актларның үтәлешен контрольдә тоту;»;

4.1.36 пунктчада «гамәлгә ашыру параметрларын» сүзләрен «чикләүләрне» сүзенә алмаштырырга;

4.1.41 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.41. Татарстан Республикасы территориясендә (федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш) федераль дәүләт аучылык контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;»;

4.2 пунктта:

4.2.3 пунктчада «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.10 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Нигезләмәгә таянып, төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра;»;

4.2.12 пунктчада «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин